КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 ноябрь г.Казань № 991

2019 елда Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1642 нче карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2019 елда Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеген (алга таба – Чаралар исемлеге) расларга.

2. Чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча вәкаләтле орган итеп Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2014 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2014 ел, 27 май, 355 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2014 ел, 27 май, 355 нче карары белән расланган 2014 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү

оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 2 август, 568 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2014 ел, 27 май, 355 нче карары белән расланган 2014 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына теркәлгән 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 10 октябрь, 751 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 27 май, 355 нче карары белән расланган 2014 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 27 декабрь, 1043 нче;

«2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2015 ел, 18 февраль, 100 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2015 ел, 18 февраль, 100 нче карары белән расланган 2015 елда авыл җирендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 30 апрель, 302 нче;

«2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2016 ел, 13 гыйнвар, 1 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру чаралары комплексын раслау турында» 2016 ел, 13 гыйнвар, 1 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 19 май, 324 нче;

«2017 елда Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеген раслау турында» 2017 ел, 27 гыйнвар, 38 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 13 ноябрь, 991 нче
карары белән расланды

2019 елда Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру буенча чаралар исемлеге

1. Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен Татарстан Республикасында тудырылган шартлар турында мәгълүмат.

1.1. Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче белем алучылар саны турында мәгълүмат:

1 таблица

| 2018/2019 уку елы башына Татарстан Республикасында төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның гомуми саны, кеше (2018 елның 1 сентябре хәленә карата) | | | | | | 2018/2019 уку елы башына белем алучыларның гомуми санында дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче белем алучылар (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш) саны, кеше (2018 елның 1 сентябре хәленә карата) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шәһәр җирендә гомуми белем бирү дәрәҗәләре | | | Авыл җирлегендә гомуми белем бирү дәрәҗәләре | | | Шәһәр җирендә гомуми белем бирү дәрәҗәләре | | | Авыл җирлегендә гомуми белем бирү дәрәҗәләре | | |
| башлан-гыч | төп | урта | баш-лан-гыч | төп | урта | баш-лан-гыч | төп | урта | башлан-гыч | төп | урта |
| 188 647 | 191 093 | 32 980 | 33 607 | 38 421 | 5 808 | 157 520 | 159 753 | 27 934 | 10 754 | 12 256 | 1 858 |

1.2. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының физик культура-спорт инфраструктурасы торышы турында мәгълүмат:

2 таблица

| Гомуми белем бирү оешмалары | Спорт инфраструктурасын модернизацияләүгә мохтаҗ булган | | | | | Спорт инфраструктурасын модернизацияләүгә мохтаҗ булмаган | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Гомуми сан | 236 | | | | | 1 162 | | |
| Авыл җирлегендә урнашкан | 84 | | | | | 794 | | |
| Физик культура һәм спорт белән дәресләр үткәрү өчен җиһазландырылган спорт корылмалары һәм урыннары | Дәресләр үткәрү өчен җиһазланды-рылган спорт корылмалары һәм урыннары булган гомуми белем бирү оешмалары саны | | Спорт корылмаларының гомуми саныннан | | | Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының спорт корылмалары | | |
| | бар-лыгы | шул исәптән авыл җирле-гендә | ремонт таләп итә торган | шулар-дан авария хәлендә булган | югары дәрәҗәдәге төзелеш әзерлегендә булган төзелүче объектлар | ремонт таләп итә торган | шулар-дан авария хәлендә булган | югары дәрәҗәдәге төзелеш әзерлеген-дә булган төзелүче объектлар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Спорт заллары | 1 674 | 891 | 236 | 0 | 8 | 84 | 0 | 3 |
| Ачык яссы спорт корылмалары (барлыгы), шулардан: | 1 791 | 1 112 | 122 | 0 | 6 | 52 | 0 | 1 |
| Футбол кыры | 553 | 347 | 44 | 0 | 2 | 19 | 0 | 1 |
| Баскетбол мәйданчыгы | 303 | 164 | 19 | 0 | 1 | 8 | 0 | 0 |
| Волейбол мәйданчыгы | 286 | 171 | 13 | 0 | 1 | 6 | 0 | 0 |
| Хәрәкәтле уеннар өчен мәйданчык | 225 | 154 | 12 | 0 | 0 | 1 | 0 | 0 |
| Хоккей яки боз мәйданчыгы | 257 | 183 | 27 | 0 | 0 | 18 | 0 | 0 |
| Тренажер мәйданчыгы | 61 | 25 | 4 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Спорт-үсеш мәйданчыгы | 106 | 68 | 3 | 0 | 2 | 0 | 0 | 0 |
| Башка спорт мәйдан-чыклары | 13 | 11 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Чаңгы трассасы | 118 | 103 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Йөгерү юллары | 429 | 255 | 21 | 0 | 0 | 7 | 0 | 0 |
| Озынлыкка сикерү өчен сектор | 336 | 222 | 15 | 0 | 0 | 6 | 0 | 0 |
| Ыргыту өчен сектор | 186 | 150 | 6 | 0 | 0 | 6 | 0 | 0 |
| Йөзү бассейннары - барлыгы, шулардан: | 34 | 3 | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 50-метрлы | 2 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 25-метрлы | 20 | 1 | 2 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| башка үлчәмдәге | 12 | 1 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |

1.3. Дәрестән тыш вакытта физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучыларның өлешен арттыруга юнәлдерелгән һәм тормышка ашырылган чаралар турында мәгълүмат.

1.3.1. Инфраструктураны үстерүгә юнәлдерелгән чаралар.

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы, муниципаль органнарның мәгариф белән идарә итүче эшчәнлеге үсеп килүче буынның

сәламәтлеген ныгыту, балаларны һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими рәвештә һәм массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән. Бүген бу эшнең билгеле бер нәтиҗәләре бар.

Физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыру өчен тиешле инфраструктураның булуы аеруча әһәмияткә ия.

1 266 гомуми белем бирү оешмасында (гомуми белем бирү оешмаларының гомуми санында 91 процент) 1 674 спорт залы эшләп килә. Гомуми белем бирү оешмаларының спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасы түбәндәге объектлардан тора:

спорт мәйданчыклары – 106;

хоккей тартмалары – 257;

футбол кырлары – 553;

бассейннар – 34;

тренажер заллары – 55;

башка объектлар – 40.

2012 елда Татарстан Республикасының гомуми белем бирү төбәк системасын модернизацияләү проекты кысаларында 33 гомуми белем бирү оешмасында агымдагы ремонт үткәрелде. Моннан тыш, 3 гомуми белем бирү оешмасында, шул исәптән авыл җирлегендә урнашкан 1 гомуми белем бирү оешмасында спорт заллары ремонтланды.

2013 елда капиталь ремонт программасы кысаларында 81 гомуми белем бирү оешмасында спорт залларына ремонт үткәрелде. Җылыту системасын, тәрәзәләрне алыштыру, түбәне ремонтлау эшләре үткәрелде.

2014 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында 31 спорт залы, 2015 елда – 38 спорт залы, 2016 елда – 22 спорт залы, 2017 елда – 14 спорт залы, 2018 елда 6 спорт залы ремонтланды.

2019 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 6 спорт залында ремонт эшләре үткәрү планлаштырыла.

2013 елдан Татарстан Республикасында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының ачык яссы спорт корылмаларын төзү һәм спорт җиһазлары белән җиһазландыру программасы тормышка ашырыла.

2013 елда Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары микрорайоннарында һәм паркларында универсаль спорт мәйданчыкларын төзү максатларында 59 ачык яссы спорт корылмасы төзелде.

2014 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасы кысаларында Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең гомуми белем бирү оешмалары территориясендә 72 ачык яссы спорт мәйданчыгы төзелде.

2013 елдан Татарстан Республикасы торак пунктларында универсаль спорт мәйданчыкларын төзү буенча республика программасы гамәлгә ашырыла. 2013 елда – 158 ачык яссы спорт мәйданчыгы, 2014 елда – 163 ачык яссы спорт мәйданчыгы, 2015 елда – 162 ачык яссы мәйданчыгы, 2016 елда – 188 ачык яссы мәйданчыгы, 2017 елда – 120 ачык яссы мәйданчыгы, 2018 елда 96 ачык яссы мәйданчыгы

төзелде. 2019 елда Татарстан Республикасы торак пунктларында 104 ачык яссы мәйданчыгын төзү планлаштырыла.

1.3.2. Гомуми һәм өстәмә белем бирү системасында оештыру чаралары.

Өстенлекле бурычларның берсе – муниципаль берәмлекләрнең спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасы объектларын максималь рәвештә файдаланып, спорт белән шөгыльләнүне массакүләм итү.

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан физик культура дәресләре үткәрү һәм дәрестән тыш спорт-сәламәтләндерү эшчәнлеген оештыру өчен муниципаль дәрәҗәдәге спорт-сәламәтләндерү объектлары: спорт сарайлары, спорт комплекслары, боз сарайлары, йөзү бассейннары, стадионнар актив кулланыла.

Гомуми белем бирү оешмаларының муниципаль спорт-сәламәтләндерү объектларыннан файдалануы турында мәгълүмат:

3 таблица

| Дәресләр үткәрү өчен спорт объектларыннан файдаланучы гомуми белем бирү оешмалары саны | 2013/2014 уку елы | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы | 2016/2017 уку елы | 2017/2018 уку елы | 2018/2019 уку елы (2018 елның 1 сентябре торышына карата) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Физик культура дәресләре үткәрә торган мәктәпләр саны/укучылар саны | 621 (41,3%)/175 176 (47%) | 624 (42,8%)/183 662 (49,7%) | 605 (43,1%)/191 592 (51,4%) | 632 (45,4%)/206 370 (53,6%) | 652 (47,3%)/219 881 (55,2%) | 666 (47,8%)/22 227 (55,7%) |
| Дәрестән тыш спорт-сәламәтләндерү эшен оештыручы мәктәпләр саны/укучылар саны | 1 454 (96%)/ 305 672 (82%) | 1 415 (97%)/ 364 735 (98,7%) | 1 363 (97,2%)/ 370 437 (98,9%) | 1 370 97,6%)/ 380 783 (98,9%) | 1 362 (98,3%)/ 384 777 (98,9%) | 1 374 (98,6%)/ 394 667 (98,9%) |

Республиканың гомуми белем бирү оешмалары спортның уен төрләрен, аерым алганда, мәктәп баскетболын үстерүгә юнәлдерелгән проектларда актив катнаша. Тугызынчы ел Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмалары командалары арасында «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионаты үткәрелә.

2017/2018 уку елы сезонының «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионатында республиканың 1 009 гомуми белем бирү оешмасыннан 1 683 мәктәп командасы катнашты (гомуми җәлеп итү – 20 196 укучы).

Татарстан Республикасында «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионатын үткәрү динамикасы:

4 таблица

| Чемпионатның нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы | 2016/2017 уку елы | 2017/2018 уку елы |
|---|---|---|---|---|
| Чемпионатта катнашучы мәктәпләр саны | 898 | 936 | 1018 | 1009 |
| Чемпионатта катнашучы командалар саны | 1 339 | 1 438 | 1 590 | 1 683 |
| Чемпионатта катнашучылар саны | 16 068 | 17 256 | 19 440 | 21 200 |
| Кайтартылган спорт формасы комплектлары саны | 432 | 432 | 432 | 432 |
| Кайтартылган туплар саны | 5 388 | 5 616 | 4 072 | 4 080 |

2018 елның 6 февральдән 8 февральгә кадәр Казан шәһәрендә «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы чемпионатының финалы узды. Җиңүчеләр – Яр Чаллы шәһәренең «28 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең егетләр командасы һәм Яр Чаллы шәһәренең «10 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең кызлар командасы – Йошкар-Ола шәһәрендә Идел буе федераль округы финалында катнашты.

«Хезмәткә һәм саклауга әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыру максатында комплекс фестивальләрен үткәрү традициягә әверелде.

2018 елның 30 мартыннан 31 мартына кадәр Яр Чаллы шәһәрендә «Зур гаилә уеннары» – «Бөтен гаилә белән ГТО» кышкы фестиваленең финалы узды. Финал ярышларында 100дән артык укучы һәм аларның ата-аналары катнашты.

2018 елның 6 июненнән 8 июненә кадәр белем бирү оешмалары укучылары арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы фестиваленең республика этабы узды. Фестивальдә Татарстан Республикасының 13 муниципаль районыннан 104тән артык укучы катнашты.

2014 елның маеннан 2018 елның июненә кадәр 65 840 укучы «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексының аерымлык билгеләренә ия булдылар.

Башлангыч гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучыларны күпләп йөзүгә өйрәтү системасын булдыру максатларында, «Йөзү буенча өйрәтү» проекты тормышка ашырыла.

«Йөзү буенча өйрәтү» проектын үстерү динамикасы:

5 таблица

| Проектта катнашучылар | 2016/2017 уку елы | 2017/2018 уку елы |
|---|---|---|
| Мәктәпләрнең гомуми саны | 603 | 931 |
| Шәһәр мәктәпләре саны | 236 | 454 |
| Авыл мәктәпләре саны | 367 | 477 |
| 2 сыйныфта укучылар саны | 17 469 | 24 409 |
| 3 - 4 сыйныфта укучылар саны | 23 928 | 38 892 |

1.3.3. Мәктәп спорт клублары челтәрен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар.

Мәктәп спорт клубларының эшчәнлеген оештыру мәктәп спортын үстерү юнәлешләренең берсе булып тора.

Мәктәп спорт клублары саны үсеше динамикасы:

6 таблица

| Күрсәткеч исеме | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы | 2016/2017 уку елы | 2017/2018 уку елы | 2018/2019 уку елы |
|---|---|---|---|---|---|
| Мәктәп спорт клублары оештырылган гомуми белем бирү оешмалары саны | 147 | 319 | 335 | 442 | 446 |

2018/2019 уку елында республиканың гомуми белем бирү оешмалары базасында 446 мәктәп спорт клубы эшли.

2018 елның 7 сентябреннән 8 сентябренә кадәр Яр Чаллы шәһәрендә мәктәп спорт клубларының Бөтенроссия спорт уеннарының республика этабы финалы узды.

Ярышларда Азнакай, Балтач, Бөгелмә, Югары Ослан, Зәй, Кайбыч, Мамадыш, Минзәлә, Түбән Кама, Саба муниципаль районнарыннан, Яр Чаллы шәһәреннән, Казан шәһәреннән 12 команда катнашты. Ярышларда катнашучыларның гомуми саны – 240 кеше.

Ярыш йомгаклары буенча түбәндәге командалар җиңүче һәм приз алучылар булды:

Яр Чаллы шәһәренең «15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе – 1 урын;

Мамадыш муниципаль районының «Мамадыш шәһәренең 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе – 2 урын;

Зәй муниципаль районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 7 нче Зәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе – 3 урын.

Ярышларда җиңүчеләр республиканы 2018 елның 8 октябреннән 12 октябренә кадәр Чиләбе шәһәрендә узган бөтенроссия финалында тәкъдим итте.

1.3.4. Бөтенроссия физкультура-спорт чаралары.

Ел саен республикада мәктәп укучыларының «Президент ярышлары» һәм «Президент спорт уеннары» бөтенроссия спорт ярышларының республика этаплары үткәрелә.

Мәктәпләр һәм укучыларның «Президент ярышлары» һәм «Президент спорт уеннары» спорт ярышларында катнашу динамикасы:

7 таблица

| Ярышлар исеме | Гомуми белем бирү учреждениеләре саны | | | | Укучылар саны | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы | 2016/2017 уку елы | 2018/2019 уку елы (2018 елның 1 сентябре торышына карата) | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы | 2016/2017 уку елы |
| Президент ярышлары | 1 459 (100%) | 1 403 (100%) | 1 391 (100%) | 1 394 (100%) | 349 509 (96,6%) | 364 064 (97,1%) | 380 875 (97,3%) |
| Президент спорт уенары | 1 459 (100%) | 1 403 (100%) | 1 391 (100%) | 1 394 (100%) | 202 687 (95,7%) | 203 211 (96,2%) | 203 697 (94,7%) |

2017/2018 уку елындагы мәктәп укучыларының «Президент ярышлары» һәм «Президент спорт уеннары» бөтенроссия спорт ярышларының республика этаплары финаллары Түбән Кама муниципаль районында һәм Яр Чаллы шәһәрендә узды. Ярышларда җиңүчеләр – «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 5 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Мөслим муниципаль районының «Мөслим лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Түбән Кама муниципаль районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 31 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе командалары – 2018 елның сентябрендә Татарстан Республикасын «Смена» һәм «Орленок» федераль үзәкләре базасында әлеге ярышларның бөтенроссия этабында тәкъдим итте.

Авыл сыйныфлары арасындагы ярышлар йомгаклары буенча Мөслим муниципаль районының «Мөслим лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе командасы 3 урынны яулады.

2. 2019 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар булдыру чараларын тормышка ашыру.

2.1. Чаралар исемлеген тормышка ашыруга якын килүләр тасвирламасы.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында авыл җирлегендә урнашкан 891 гомуми белем бирү оешмасының спорт заллары бар, шуларның 84 гомуми белем бирү оешмасында спорт залларына ремонт ясау таләп ителә.

Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балаларны һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими рәвештә һәм массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен максатларында, түбәндәге чаралар үткәрелде:

2014 елда 31 спорт залы ремонтланды;

2015 елда – 38 спорт залы;

2016 елда – 22 спорт залы;

2017 елда – 14 спорт залы;

2018 елда – 6 спорт залы;

2019 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының 6 спорт залын ремонтлау планлаштырыла.

Чараларның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

физик культура һәм спорт белән тулысынча шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итү;

укучыларның хәрәкәт активлыгы дәрәҗәсен билгеләү;

спортның иң алга киткән һәм популяр булган җәйге олимпия төрләрендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән бер гомуми белем бирү оешмасы укучыларыннан булдырылган иң яхшы гомуми белем бирү оешмалары командаларын билгеләү;

массакүләм мәктәп спортын үстерү;

сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

укучыларны физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү.

2.1.1. 2019 елда авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының физкультура-спорт инфраструктурасын үстерүгә якын килү алымнары тасвирламасы.

Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балаларны һәм яшүсмерләрне физик культура һәм спорт белән даими рәвештә һәм массакүләм шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен максатларында, Татарстан Республикасында түбәндәгеләрне үткәрергә кирәк:

авыл җирлегендә урнашкан спорт залларын ремонтлауны;

авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары территориясендә, җиһазлар, инвентарь һәм җайланмалар белән тәэмин итеп, универсаль спорт мәйданчыклары һәм блоклы модульле чаңгы базаларын төзүне.

Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче балалар өлешенең югары булмаган күрсәткечләреннән берсе – авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларын матди-техник яктан тәэмин итү җитәрлек дәрәҗәдә булмау, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларының матди-техник, физкультура-спорт базасы дәрәҗәсенең укучыларның ихтыяҗлары дәрәҗәсенә туры килмәү.

Авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру программасында катнашу авыл балаларына, муниципаль берәмлекләрнең спорт-сәламәтләндерү инфраструктурасы объектларын максималь кулланып, спорт белән шөгыльләнүне массакүләм итәргә һәм 2019 ел ахырына субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең «Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яшәүче мәктәп яшендәге укучыларның гомуми санында дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучыларның өлешен арттыру (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш)» күрсәткечен 1,4 процентка кадәр җиткерергә мөмкинлек бирәчәк, шул исәптән:

башлангыч гомуми белем бирү буенча – 1,1 процентка кадәр;

төп гомуми белем бирү буенча – 1,7 процентка кадәр;

урта гомуми белем бирү буенча – 1,4 процентка кадәр.

2.1.2. Авыл җирлегендә урнашкан һәм 2019 елда чаралар гамәлгә ашырылачак гомуми белем бирү оешмалары (гомуми белем бирү оешмаларын сайлап алу тәртибе) турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасында авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларының спорт залларының техник торышына ел саен мониторинг үткәрелә. Муниципаль берәмлекләр тәкъдимнәре буенча спорт залларында капиталь ремонт таләп ителә торган гомуми белем бирү оешмалары исемлеге төзелә. Техник торышына һәм финанслау күләменә карап, спорт залларына капиталь ремонт ясалырга тиешле гомуми белем бирү оешмалары билгеләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы кабул ителгәннән соң, алга таба генераль подрядчыны билгеләп һәм, ремонт эшләрен башкару вакытларын күрсәтеп, дәүләт контрактын төзеп, сәүдә итү процедурасы өчен техник документлар эшләү гамәлгә ашырыла.

2.1.3. Укучыларны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар тасвирламасы.

Мәктәп спорт клубларын үстерү буенча түбәндәге юнәлешләр буенча эш дәвам итәчәк:

клублар тарафыннан спорт, физкультура һәм сәламәтләндерү чараларын оештыру һәм уздыру;

клубларны заманча спорт җиһазлары һәм җайланмалары белән җиһазландыру;

сәламәтлекләренең халәтендә тайпылышлар булган, сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны физик тернәкләндерү эшен үткәрү, аларны массакүләм физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларында катнашуга җәлеп итү;

спортның төрле төрләре буенча командалар формалаштыру һәм аларның төрле дәрәҗәдәге ярышларда катнашуын тәэмин итү;

гомуми белем бирү оешмаларында физик культура, спорт, сәламәт яшәү рәвешенең төп идеяләрен пропагандалау.

2.1.4. Мәктәп спорт клублары челтәрен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар тасвирламасы.

Мәктәп спорт клублары эшчәнлегенең төп юнәлешләре:

гомуми белем бирү оешмаларында спорт төрләрен үстерү (бадминтон, милли көрәш, волейбол, баскетбол, мини-футбол һәм башка төрләр);

гомуми белем бирү оешмаларында спорт-массакүләм эшләр оештыру.

2.2. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре:

8 таблица

| Т/с | Нәтиҗәлелек күрсәткече исеме | Күрсәткечнең план мәгънәсе | Күрсәткечнең пландагы мәгънәсенә ирешү вакытлары (көне.ае.2019) | Татарстан Республикасы бюджеты турында законда каралган бюджет ассигнованиеләре күләме, мең сум |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Авыл җирлегендә урнашкан һәм спорт заллары ремонтланган гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | 6 | 01.10.2019 | 8 783,5, шул исәптән: 5 094,4 - федераль бюджеттан, |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 3 689,1 - Татарстан Республикасы бюджетыннан |
| 2. | Авыл җирлегендә урнашкан һәм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен булган аудиторияләре спорт заллары итеп үзгәртеп ясалган гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | | - | - | - |
| 3. | Укучыларның гомуми санында дәрестән тыш вакытта (гомуми белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча) физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче укучылар өлеше арту (мәктәпкәчә белем бирүдән тыш), процент | башлангыч гомуми белем бирү | 1,1 | 01.10.2019 | - |
| | | төп гомуми белем бирү | 1,7 | 01.10.2019 | - |
| | | урта гомуми белем бирү | 1,4 | 01.10.2019 | - |
| 4. | Авыл җирлегендә урнашкан һәм физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен гомуми белем бирү оешмаларында булдырылган мәктәп спорт клублары саны арту, берәмлек | | 6 | 01.10.2019 | - |
| 5. | Авыл җирлегендә урнашкан һәм ачык яссы спорт корылмалары спорт инвентаре һәм җиһазлары белән җиһазландырылган гомуми белем бирү оешмалары саны, берәмлек | | - | - | - |

3. Оешмаларда физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру процессын алып баруга һәм мониторинглауга юнәлдерелгән чаралар турында мәгълүмат:

9 таблица

| Т/с | Чара исеме | Күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре күләме, мең сум | Чара башлану көне | Чарага йомгаклар ясау көне (2019 елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру процессын алып баруга һәм мониторинглауга юнәлдерелгән чаралар | 5 094,4 (федераль бюджет), 3 689,1 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 01.01.2019 | 2019 елның 15 декабренә кадәр |